| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.06.2023 Баулы шәһәре № 189

Баулы муниципаль районы
Советының «Баулы муниципаль
районы территориясендә муниципаль
торак контролен гамәлгә ашыру
турында» 2021 елның 14 декабрендәге
93 номерлы карарына үзгәрешләр
һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районы Советының «Баулы муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 14 декабрендәге 93 номерлы карарына (2022 елның 11 апрелендәге № 111 карар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

1.2. пунктта:

беренче абзацта «энергетика нәтиҗәлелеге» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турындагы законнар» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 12) пункт өстәргә:

«12) йорт эчендәге һәм (яисә) фатир эчендәге газ җиһазларын имин эксплуатацияләүгә һәм аларга техник хезмәт күрсәтүгә таләпләр, шулай ук күпфатирлы йортта вентиляция һәм төтен каналларын тотуга карата таләпләр.»;

1.6. пунктта «1 - 11» саннарын «1 - 12» саннарына алмаштырырга;

5 нче бүлекне яңа редакциядә бәян итәргә:

«V. Башкарма комитет карарларына, муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерү

5.1. Контроль орган карарларына, муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 9 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

5.2 Контрольдә торучы затлар, алар фикеренчә, муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылган очракта, түбәндәгеләргә судка кадәр шикаять бирергә хокуклы:

1) контроль чаралар уздыру турында карарларга;

2) контроль чаралар актларына;

3) контроль чаралар кысаларында вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына).

5.3. Шикаять контрольдә торучы зат тарафыннан Контроль органына дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын һәм (яисә) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталларын кулланып электрон рәвештә тапшырыла.

Гражданин шикаять биргәндә, ул гади электрон имза, яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш. Оешма тарафыннан шикаять бирелгәндә, ул көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш.

Шикаятькә беркетелә торган материаллар, шул исәптән фото- һәм видеоматериаллар, контрольдә тотыла торган зат тарафыннан электрон рәвештә күрсәтелә.

Дәүләт серен яисә закон тарафыннан саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар булган шикаять дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең

региональ порталыннан файдаланмыйча, дәүләт сере һәм закон белән саклана торган башка сер турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып бирелә. Шикаять Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе шәхси кабул иткәндә контрольдә торучы зат тарафыннан, шикаятьтә (документларда) дәүләт серен һәм закон тарафыннан саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләрнең булуы турында Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә алдан хәбәр итеп, тапшырыла.

5.4. Башкарма комитет карарына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе (башкарма комитет җитәкчесе урынбасары) тарафыннан карала.

5.5. Башкарма комитет карарына, аның вазыйфаи затларының гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять башкарма комитет җитәкчесе (җитәкче урынбасары) тарафыннан карала.

5.6. Башкарма комитет карарына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять контрольдә торучы зат үз хокукларын бозу турында белгән яки белергә тиеш булган көннән алып утыз календарь көн эчендә бирелергә мөмкин.

Шикаять бирү срогын җитди сәбәп аркасында уздырган очракта, шикаятьне биргән затның үтенече буенча бу срок башкарма комитет тарафыннан торгызылырга мөмкин.

Шикаять биргән зат шикаять буенча карар кабул ителгәнче аны кире алырга мөмкин. Шул ук вакытта шикаятьне шул ук сәбәп белән кабат җибәрү рөхсәт ителми.

Шикаятьтә башкарма комитетының дәгъва белдерелә торган карарын үтәүне туктатып тору турындагы үтенеч булырга мөмкин.

5.7. Башкарма комитет шикаятьне теркәгән көннән соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча карар кабул итә:

1) башкарма комитетның дәгъвалана торган карарының үтәлешен туктатып тору турында;

2) башкарма комитетының дәгъвалана торган карарын үтәүне туктатып торудан баш тарту турында;

Шикаять белдерелә торган карарның үтәлешен туктатып тору турында үтенечнамә буенча карар, кабул ителгән вакыттан алып бер эш көне эчендә, шикаять биргән затка җибәрелә.

5.8. Шикаятьтә булырга тиеш:

1) карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) дәгъва белдерелә торган контрольлек итүче орган исеме, җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

2) шикаять биргән затның фамилиясе, исеме, атасының исемен (булган очракта), яшәү урыны (эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны) турында белешмәләрне, йә мөрәҗәгать итүче оешманың исеме, әлеге оешманың урнашу урыны турында белешмәләр, йә шикаять ышанычнамә буенча бирелгәндә, ышанычнамә реквизитлары һәм шикаять бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), шикаятьне карау вакытына үзара эшчәнлекне башкаруның ысулы һәм аның буенча карар алу ысулы;

3) контроль органның һәм (яисә) аның вазыйфаи затының шикаять биргән контрольдә тотыла торган затның хокукларын бозуга китергән яисә китерергә мөмкин дәгъвалана торган карарлары турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүченең контроль орган карары һәм (яисә) вазыйфаи затның гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәү сәбәбе нигезләрне һәм дәлилләрне. Гариза бирүче аның дәлилләрен раслый торган документларны (булган очракта) йә аларның күчермәләрен тапшыра ала;

5) шикаять биргән затның таләпләре;

6) шикаять бирелә торган контроль чарасының Контроль (күзәтчелек) чаралары бердәм реестрында исәпкә алу номеры, әгәр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан башкасы билгеләнмәгән булса.

Шикаятьтә цензурасыз яисә мыскыллы сүзләр, башкарма комитетның вазыйфаи затлары яисә аларның гаилә әгъзаларының тормышы, сәламәтлеге һәм мөлкәтенә карата янаулар булырга тиеш түгел.

Шикаять контрольдә тотыла торган затның вәкаләтле вәкиле тарафыннан тапшырылырга мөмкин. Мөның өчен аңа «Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы» Федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә тиешле хокук бирелергә тиеш.

Шикаятькә Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең, аның иҗтимагый вәкиленең, Татарстан Республикасы башлыгының (Рәисенең) эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкиленең шикаять предметына караган позициясе теркәлергә мөмкин.

Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, аның иҗтимагый вәкиле, Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) каршындагы вәкаләтле вәкил позициясенә җавап шикаятьне биргән затка, шикаять буенча карар кабул ителгән вакыттан алып бер эш көне эчендә, контроль орган тарафыннан җибәрелә.

5.9. Контроль органы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) (алга таба - шикаятьне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат) шикаятьне алган вакыттан алып биш эш көне эчендә түбәндәге очракларда шикаятьне караудан баш тарту турында карар кабул итә:

1) шикаять әлеге Нигезләмәнең 5.6. пунктында күрсәтелгән шикаять бирү срогы тәмамланганнан соң бирелсә һәм аны торгызу турында яисә шикаятьне бирүнең билгеләнгән срогын торгызуга турында үтенечнамә булмаса;

2) шикаять бирү вакытын торгызу турындагы үтенечнамәне канәгатьләндерүдән баш тартылса;

3) шикаять биргән контрольдә торучы заттан шикаять буенча карар кабул ителгәнчегә кадәр шикаятьне кире алу турында гариза килсә;

4) шикаятьтәге мәсьәләләр буенча суд карары булса;

5) Контроль органга элек шул ук контрольдә тотыла торган заттан шул ук нигезләрдә башка шикаять бирелсә;

6) шикаятьтә цензурасыз яисә мыскыллы сүзләр, контроль органның вазыйфаи затларының, шулай ук аларның гаилә әгъзаларының тормышы, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янау булса;

7) элек әлеге контрольдә тотыла торган затның шикаятенә карата баш тарту турында кабул ителсә, кабат бирелгән шикаятьтә яңа дәлилләр китерелмәсә;

8) шикаять тиешле Контроль органга бирелмәсә;

9) Россия Федерациясе законнары буенча контроль орган карарларына шикаять белдерү буенча суд тәртибе генә каралса.

Әлеге пунктның 3-8 бүлекләрендә күрсәтелгән нигезләрдә шикаятьне караудан баш тарту судка кадәр шикаять бирү нәтиҗәсе булып тормый һәм Контроль органы карарларына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка шикаять белдерү өчен нигез була алмый.

5.10. Контроль органының шикаятьне карауга вәкаләтле вазыйфаи заты шикаятьне караганда контроль (күзәтчелек) эшчәнлегенә судка кадәр шикаять бирүнең ярдәмче системасыннан файдалана (моңа шикаятьне карау дәүләт серен яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар белән бәйле очраклар керми).

Контроль орган судка кадәр шикаять бирү системасына шикаятьне карау барышы турында белешмәләр тапшыруны тәэмин итә.

Дәүләт серен яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар булган шикаятьне карау, Россия Федерациясенең дәүләт серен яки закон тарафыннан саклана торган башка сер турындагы законнары таләпләрен үтәп, контроль (күзәтчелек) эшчәнлеге системасыннан файдаланмыйча, контроль органы җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5.11. Шикаять Контроль орган тарафыннан теркәлгәннән соң егерме эш көне эчендә каралырга тиеш.

Күрсәтелгән срок түбәндәге аерым очракларда егерме эш көненә озайтылырга мөмкин:

1) шикаятьтә күрсәтелгән фактлар буенча вазыйфаи затның гамәлләренә (гамәл кылмаувына) карата хезмәт тикшерүе үткәрү;

2) гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерелә торган вазыйфаи затның нигезле сәбәп буенча эш урынында булмавы (авыру, отпуск, командировка);

3) башка органнар карамагындагы белешмәләрне алу таләп ителсә.

5.12. Контроль орган шикаять биргән контрольдә торучы заттан шикаять предметына кагылышлы өстәмә мәгълүмат һәм документлар сорарга хокуклы.

Контрольдә торучы зат күрсәтелгән мәгълүматны һәм документларны сорату җибәрелгәннән соң биш эш көне эчендә тапшырырга хокуклы.

Шикаятьне карау срогы шикаять предметына караган өстәмә мәгълүмат һәм документлар тапшыру турында гарызнамә җибәрелгәннән соң туктатыла һәм аларны Контроль органы алганан соң торгызыла, әмма сорату җибәрелгәннән соң биш эш көненнән дә артыграк срокка түгел.

Контрольдә торучы заттан шикаять предметына кагылышлы өстәмә мәгълүмат һәм документлар алынмау шикаятьне караудан баш тарту өчен нигез булып тормый.

Шикаятьне биргән контрольдә торучы заттан дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яки аларга буйсынучы оешмалар карамагында булган мәгълүматны һәм документларны соратып алу рөхсәт ителми.

Шикаять биргән зат, шикаять буенча йомгаклау карары кабул ителгәнчегә кадәр, шикаять предметына караган өстәмә материалларны тәкъдим итәргә хокуклы.

5.13. Кабул ителгән карарның һәм (яисә) кылынган гамәлнең (гамәл кылмауның) законлылыгын исбатлау бурычы карары, вазыйфаи затының гамәленә(яисә) гамәл кылмавына дәгъва белдерелә Контроль органга йөкләнә.

5.14. Шикаятьне карау йомгаклары буенча Контроль орган түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләнми;

2) Контроль орган карарын тулысынча яисә өлешчә юкка чыгара;

3) Контроль орган карарын тулысынча юкка чыгара һәм яңа карар кабул итә;

4) Контроль орган вазыйфаи затларының гамәлләрен (гамәл кылмавын) законсыз дип таный һәм, карар чыгара, шул исәптән билгеле бер гамәлләрне башкару турында.

5.15. Кабул ителгән карарны нигезли торган контроль орган карары, аны үтәү срогы һәм тәртибе Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталында һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында контрольдә тотыла торган затның шәхси кабинетында карар кабул ителгән көннән алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

Дәүләт серен яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар булган шикаятьне карау йомгаклары буенча контроль орган карары, дәүләт серен яисә закон тарафыннан саклана торган башка сер турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәгән хәлдә, контрольдә торучы затка кәгазь чыганакта җибәрелә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

3. 1.2., 1.6. пунктлары 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Советының икътисадый үсеш, эшкуарлык, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башлыгы, район Советы Рәисе — И.И. Гозәеров